**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**

Азнакай шәһәре № 256-35 «22 » апрель 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» 2011 елның 20 декабрендәге 93-15 номерлы карары белән расланган балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» (12.07.2012 № 166-22, 10.08.2012 №178-23, 19.10.2012 №185-25, 05.02.2013 №219-32, 23.08.2013 №259-36, 12.08.2014 №321-45, 15.07.2015 №380-53, 09.12.2016 №83-13, 21.02.2018 №176-26, 28.12.2018 №232-33 карарлар редакциясендә)

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында " 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» 2011 елның 20 декабрендәге 93-15 номерлы карары белән расланган, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына, Гәрәева Гөлнара Сәгадәтовнаның үз вәкаләтләрен туктату турында язма гариза бирүгә бәйле рәвештә, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Г.С. Гәрәеваны комиссия составыннан чыгарырга.

1.2. Комиссия составына кертелүгә язма ризалык исәпкә алып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына кертергә:

- Райманов Сирин Анасович – Россия Эчке эшләр министрлыгының Азнакай районы буенча бүлеге полиция начальнигы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча) аны килешү буенча комиссия әгъзасы итеп расларга.

2. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Азнакай район Советы карарына
кушымта
«_____» __________ 2019 №____

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча
КОМИССИЯ СОСТАВЫ

*Комиссия рәисе:*

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Гыйлаҗев Дамир Рашат улы | - | Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| *Комиссия рәисе урынбасары:* | | | |
| 2. | Марданшина Элиза Наил кызы | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Азнакай муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы |
| *Комиссиянең җаваплы секретаре:* | | | |
| 3. | Солтангирова Эльвира Илгизәр кызы | - | Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты баш белгече |
| *Комиссия әгъзалары:* | | | |
| 4. | Батыров Айрат Фәтхелислам улы | - | Азнакай муниципаль районы «Форпост» МБУ директоры |
| 5. | Рахманов Альберт Магалим улы | - | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе начальнигы |
| 6. | Райманов Сирин Әнәс улы | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Азнакай районы буенча бүлеге полиция начальнигы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча) |
| 7. | Гарипов Флорис Алмарис улы | - | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге начальнигы |
| 8. | Рамазанова Фәния Әнис кызы | - | "Азнакай РҮХ" табиб - наркологы |
| 9. | Гафиева Лилия Рафис кызы | - | “Азнакай шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” директоры |
| 10. | Солтанова Алсу Мирсәяф кызы | - | УИИ №2 ФБУ «МРУИИ №9 ГУФСИН России по РТ» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | начальнигы |
| 11. | Халимова<br>Лилия Рәис кызы | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Азнакай муниципаль районындагы «Өмет» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлеге мөдире |
| 12. | Хафизова<br>Гөлсинә Сәетҗан кызы | - | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы |
| 13. | Сәгыйтов<br>Илнур Газинур улы | - | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча идарәсе башлыгы |
| 14. | Баһаветдинов<br>Камил Флер улы | - | Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең Азнакай районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| 15. | Галиева<br>Эльвира Сәйлүн кызы | - | Татарстан Республикасы Азнакай район Советының оештыру бүлеге начальнигы |